# قاموس
# عربي-تتاري
## للنصوص الدينية

يحتوى حوالى ١٤٠٠٠ كلمة

قزان
٢٠١٦

# ДИНИ ТЕКСТЛАРГА ГАРӘПЧӘ-ТАТАРЧА СҮЗЛЕК

14000 чамасы сүз

Казан
2016

УДК 811.411.21:811.512.145(03)
ББК 81.2Араб:81.2Тат
Д47

*Россия Федерациясенең «Авторлык хокуклары һәм арадаш хокуклар турында»гы Законы белән саклана. Китапка кергән материалларны тулысы белән яки өлешчә башка басмалар өчен файдалану, төрле электрон мәгълүмат чыганакларына күчереп яки төшереп алу авторлык хокукларына ия булган затның язма рөхсәтеннән башка катгый тыела*

Сүзлек шәригать фәннәре белгече
**Сәлим Сәлимҗан улы Гайнуллин**ның
инициативасы һәм ярдәме белән төзелде

Төзүче
*филология фәннәре кандидаты*
***Ринат Сәфәр***

Д47 Дини текстларга гарәпчә-татарча сүзлек / төз.: Ринат Сәфәр. – Казан, 2016. – 652 б.
ISBN

Сүзлектә барлыгы 14000 чамасы гарәп сүзе татарчага тәрҗемә ителеп бирелгән. Нигездә, бу – Коръәне Кәрим һәм хәдисләрдә кулланылган лексик берәмлекләр, шулар исәбендә кеше, хайван, төрле географик объектлар һ.б. ш. ялгызлык исемнәре дә бар. Чикле күләмдә хәзерге илаһият терминологиясе дә урын алган. Гарәп дөньясына гына хас атама булган, хәзерге телдә кулланылмый торган реалийларны белдергән сүзләргә җәяләр эчендә аңлатмалар бирелгән.

Киң катлау укучылар өчен чыгарыла. Аеруча югары уку йортлары студентлары, мәдрәсә шәкертләре, укытучы-мөгаллимнәр, тәрҗемәчеләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерә ала. Сүзлекнең максаты – дини текстлардагы гарәп сүзләрен тәрҗемә иткәндә татар телендә эквивалентларын бирү, гарәпчәдән алынган сүзләрнең язылышларын чагылдыру.

ISBN

© Сәфәр Р. Т., 2016

## КЕРЕШ СҮЗ

Гарәп теле – дөньяда иң киң таралган телләрдән берсе. Ул сами-хами (семит-хамит) телләр семьясына керә. Шактый гына диалектлары булса да, әдәби гарәп теле – бер генә. Ул бөтен гарәп илләренең һәм БМО Генераль Ассамблеясенең рәсми теле хезмәтен үти. Хәзерге гарәп теле борынгы, яки классик, гарәп теленнән үсеп чыккан. Коръәне Кәрим, «Мең дә бер кичә» кебек язма чыганаклар нәкъ менә шушы борынгы гарәп телендә язылган.

Татар теленә гарәп сүзләре сизелерлек дәрәҗәдә IX–X гасырларга үтеп керәләр. Сәүдә, сәясәт, мәдәният багланышлары гарәпчәнең Идел болгарлары теленә көчле йогынты ясавына этәргеч булса да, бу, беренче нәүбәттә, Болгарда ислам диненең өстенлек итә башлавы белән бәйле. XIII–XIV гасырларда ислам Алтын Урданың рәсми дине булып киткәч, гарәп язуы, гарәп теле аеруча таралыш ала. XVII–XIX гасырларга гарәп алынмаларының иске татар телендә саны меңнәр белән исәпләнә. Хәтта язма телдә шактый гына гомумкулланыштагы төрки-татар сүзләре гарәпчәләргә алмаштырылган була.

Шушындый дәвамлы вакыт эчендә гарәпчә сүзләрне дөрес аңлау, дөрес куллану максаты белән төрле сүзлекләр дә төзелә килә. Борынгырак чорда мондый сүзлекләр гарәпчә-төркичә булса, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында инде гарәпчә-татарча сүзлекләр дә мәйданга килә. Нигездә бу сүзлекләр гарәп теленнән кергән алынмаларга аңлатма

биру рәвешендә төзелгәннәр. Мәсәлән, Г. Барудиның «Лөгат сөляс» (1897 елдан алып берничә тапкыр нәшер ителгән), С. Җантуринның «Лөгать» (1911), Г. Сәйфуллинның «Кечек лөгать» (1912) кебек хезмәтләре шундый сүзлекләрдән.

Т. Ильясиның «Әл-Мөфид. Гарәпчә-татарча мөкәммәл лөгать китабы» аерым урын алып тора. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлагач, 1903 елда Т. Ильяси Гарәбстанга һәм Мисырга китә. Анда ул гарәп теленең тарихы, диалектлары һәм яңа әдәби гарәп теле буенча шактый күп материал туплый. Шулар нигезендә ул күптомлык гарәпчә-татарча һәм татарча-гарәпчә сүзлекләр төзергә керешә. Бу күптомлыкларның фәкать югарыда телгә алынган беренче томы гына бастырылган. Автор сүзлекләрне төзеп бетергән булса да, билгесез сәбәпләр аркасында калган томнар нәшер ителмичә калганнар һәм аларның кульязмалары да югалган дип санала[1].

Совет чорында һәм Совет чорыннан соң кабат нәшер ителеп һаман да актуальлеген җуймаган К. Хәмзин, М. Мәхмүтов һәм Г. Сәйфуллиннарның «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»нә (1965, 1993) XIII гасыр шагыйре Кол Галидән башлап хәзерге чор әдипләренең әсәрләреннән, шулай ук төрле дәреслекләрдән, элекке чор вакытлы матбугат битләреннән тупланган сүзләр алынган. Бу үзенең шактый тулылыгы белән башкалардан аерылып торган белешмәлек һәм Җ. Зәйнуллинның «Шәрык алынмалары сүзлеге» (1994) икесе дә гарәп һәм фарсы телләреннән алынып иске яки хәзерге татар телендә кулланышта йөргән сүзләрне генә чагылдыралар.

Бүгенге көндә гарәп теле татар халкы арасында элекке югары урынын инде биләми. Хәзер гарәпчә күбрәк дин

[1] Әхмәтҗанов М. Таһир Ильяси // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2010. – № 3/4. – 167–170 бб.

өлкәсендә, мәдрәсәләрдә гамәлдә йөри. Шуны күз уңында тотып, без бу сүзлекне нәкъ дини текстларны – иң элек Коръәне Кәримне һәм хәдисләрне – укыганда һәм тәрҗемә иткәндә кирәге чыгачак белешмәлек итеп әзерләдек, аңа бөтен гарәп сүзләрен кертү максат итеп куелмады. Лөгатьлек буларак В. Ф. Гиргасның «Словарь к Арабской хрестоматии и Корану» хезмәтенең төзәтелеп яңадан бастырылган «Арабско-русский словарь к Корану и хадисам» сүзлеге нигез итеп алынды. Чикле күләмдә генә хәзерге илаһият терминологиясенә дә урын бирелде. В. Ф. Гиргасның сүзлегендә кайбер баш сүзләрнең антонимнары һәм синонимнары китерелә. Без дә аларны төшереп калдырмадык. Кайбер сүзләр янындагы аларның кайсы телдән гарәп теленә алынганлыгын күрсәтә торган тамгалар да В. Ф. Гиргастан алынды.

Киләчәктә бу хезмәтебез гарәпчә-татарча, татарча-гарәпчә тулырак, гарәп теленең хәзерге лексикасын, фразеологиясен, терминологиясен дә эченә алган сүзлекләр төзелүенә үз өлешен кертер дип өмет итәбез.

## СҮЗЛЕКНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ ТУРЫНДА

1. Сүзлектә калын хәрефләр белән билгеләнгән баш сүзләр тамырларына карап алфавит тәртибендә урнаштырылган.

2. Гарәп исемнәре һәм сыйфатлары берлек санда, баш килештә, билгесезлек хәлендә бирелгән. Еш кына мөзәккәр исемнәр янында мөәннәс формалары күрсәтелгән (*мнс.*). Мәсәлән:

**أَنْكَرُ** *мнс.* نَكْرَآءُ начар, алама, әшәке
**وَالِدٌ** *мнс.* ة тудыручы, ата, әти

Әгәр исемнең күплек саны кушымчалар кушу юлы белән ясалса, мондый сүзнең күплек сан формасы күрсәтелмичә баш сүз янына *күп. дрс.* тамгасы куелган, әгәр исемнән ватык күплек саны ясалса, мондый күплек сан формалары *күп.* тамгасы белән баш сүз янында күрсәтелгән. Кайбер очракларда икелек саны да күрсәтелеп үткән. Мәсәлән:

**مُوضِحَةٌ** *күп. дрс.* төзәлми торган яра
**أُنْبُوبٌ** *күп.* أَنَابِيبُ буын арасы (*үсемлекләрдә*)
**أَوْلَى** *ик.* أَوْلَيَانِ *күп.* أَوَالِ иң якын; иң лаек, киелешле, яхшы; хокуклы

Җыйма предметларны белдергән исемнәрнең бер данәсе *берс.* тамгасы белән бирелгән. Мәсәлән:

**دُرٌّ** *күп.* دُرَرٌ *җый.* энҗе; *берс.* دُرَّةٌ энҗе бөртеге

Гарәп саннары берлек санда, баш килештә, билгесезлек хәлендә бирелгән.

3. Гарәп фигыльләре 3 затның берлек санында, үткән заманда, мөзәккәр формада бирелгән. Фигыль янында рим саннары белән аның бабы күрсәтелгән (I бап күрсәтелмәгән). Әгәр гарәп фигыле I бапта кулланылмаса, җәяләр эчендә хәрәкәсез генә аның тамыры бирелгән һәм мәкалә кулланылган бап формасыннан башланып киткән. Мәсәлән:

> **نَهَكَ** ... ябыктыру, йончыту (*авыру*); авырттырып, каты итеп җәзалау; VIII اِنْتَهَكَ ябыктыру, йончыту...
>
> (**وحش**) IV أَوْحَشَ кешесез калу (*урын, төбәк*); V تَوَحَّشَ кыргыйлашу ...; X اِسْتَوْحَشَ кешеләр тарафыннан кире кагылу...

Авыш *а, у* яки *и* хәрефләре белән хәзерге киләчәк заманның уртадагы хәрәкәсе күрсәтелгән.

I бап фигыльләре янында ешрак кулланыла торган масдарлар китерелгән. Калган масдарлар мәкалә эчендә алфавит тәртибендә бирелгән. Мәсәлән:

> (**دعو**) دَعَا *у*, *масд.* دَعْوَى, دُعَآءٌ чакыру, дәгъвәт итү; өндәү; дога кылу...

4. Сүзлек мәкаләсе яңа юлдан башлана. Тамыр сүздән ясалган дериватлар яңа мәкаләдә бирелә һәм алар алдына тире (–) куелган.

Бер үк төрле хәрефләрдән гыйбарәт булган, ләкин төрлечә хәрәкәләнгән сүзләр түбәндәге тәртиптә бирелгән: ْ сәкен, َ фәтхә, ُ даммә, ِ кәсрә, ّ шәддә, мәсәлән:

> – **رَبْعٌ** *күп.* رِبَاعٌ язгы яшәү урыны, күчмәннәр торагы...
>
> – **رُبْعٌ** һәм **رُبُعٌ** *күп.* أَرْبَاعٌ пәнҗешәмбе, атна кич

– **رُبَعٌ** *мнс.* ة язгы бута
– **رُبُعٌ** *к.* رُبْعٌ
– **رِبْعٌ** дүрт көнлек период...

Гарәп теленә бик күптәннән кергән алынмаларның чыганак телләре күрсәтелгән. Мәсәлән:

**أَنْبَارٌ** *фар.* амбар; кибет
**زُنَّارٌ** *күп.* زَنَانِيرُ *грек.* зөннар...

Сүзлек мәкаләсендә өтер аша синонимнар санап кителгән, нокталы өтер аша төрле мәгънәләр бирелгән. Мәсәлән:

**نَجِدَ** *а, масд.* نَجَدٌ тирләп чыгу; ялыгу, ару, алҗу, йончу, хәлдән таю; авырту, әрнү тою

Тәрҗемәсе генә аңлашылмый торган сүзләргә аңлатмалар курсив белән түгәрәк җәяләр эчендә яки җәяләрсез бирелгән. Мәсәлән:

**لِثَامٌ** лисам, *авыз белән борынны каплый торган пәрдә*

## ӘДӘБИЯТ

Баранов Х. К. Арабско-русский словарь. Около 42 000 слов. Изд. 5-ое, перераб. и доп. / Х. К. Баранов. – М., Русский язык, 1976. – 944 с.

Гиргас В. Ф. Арабско-русский словарь к Корану и хадисам / В. Ф. Гиргас. – СПб., Диля, 2010. – 928 с.

Зәйнуллин Җ. Г. Шәрык алынмалары сүзлеге / Җ. Г. Зәйнуллин. – Казан, Мәгариф, 1994. – 143 б.

Ислам. Белешмә-сүзлек / төз. З. Шәфигый. – Казан, Татар. кит. нәшр., 1993. – 191 б.

Мәхмүтов М. И., Хәмзин К. З., Сәйфуллин Г. Ш. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге / М. И. Мәхмүтов, К. З. Хәмзин, Г. Ш. Сәйфуллин. – Казан, 1965, 1993. – 854 б.

Миллият сүзлеге: Аңлатмалы сүзлек / төз. А. Тимергалин. – Казан, Мәгариф, 2007. – 575 б.

Сафиуллина Р. Р. Мөселман терминологиясе сүзлеге. Словарь мусульманской терминологиию / Р. Р. Сафиуллина. – Казан, Алма-Лит, 2005. – 124 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. – Казан, Татар. кит. нәшр., 1977, 1979, 1981. – 726 б., 476 б., 832 б.

Ҳасан Б. Арабча-ўзбекча бошланғич луғат / Ботирбек Ҳасан. – Тошкент, Мовароуннаҳр, 1996. – 584 б.

Mutçalı S. Arapça-türkçe sözlük / Serdar Mutçalı. – İstanbul, Dağarcık yayınları, 1995. – 1054 s.

Yeğin A. Osmanlıca-Türkçe islamî-ilmî-edebî-felsefî yeni lûgat / Abdullah Yeğin. – İstanbul, Hizmet Vakfı yayınları, 1991. – 790 s.

الإلياسى ط. ا. المفيد. عربچه-تاتارچه مكمّل لغت كتابى. الجزءالاوّل / طاهر احمد الإلياسى. – قزان، «ملّت» مطبعه‌سى، ۱۹۱۲. – ۸۲٤ ص.

البارودى ع. لغات ثلاث. سه زبان. اوچ تيل / عالم جان البارودى. – قزان، «ملّت» مطبعه‌سى، ۱۹۱٦ – .۳۲۰ ص.

جانتورين س. لغت / سليم گراى جانتورين. – اوفا، «شرق» مطبعه‌سى، ۱۹۱۱. – ٤٦٦ ص.

سيف اللين ع. كچك لغت. ادبياتمزده مستعمل عربى، فارسى و ياوروپاليلر سوزلرينى جامع لغت كتابيدر / عباس سيف اللين. – قزان، «ملّت» مطبعه‌سى، ۱۹۱۲ – .۱۱۲ ص.

## КЫСКАРТЫЛМАЛАР

*ант.* – антоним
*бәр.* – бәрбәрчә
*бер.* – берлек сан
*берс.* – берсе, бер данәсе
*бот.* – ботаника
*грам.* – грамматикада
*грек* – грекча
*дини* – дини, дингә караган сүз
*дөрс.* – дөресрәк варианты
*җый.* – җыйма
*ик.* – икелек сан
*к.* – карагыз
*кечер.* – кечерәйтү
*кулл.* – кулланыла
*күп.* – күплек сан
*күп. дрс.* – бөтен яки дөрес күплек саны
*күч.* – күчерелмә мәгънәдә
*кыск.* – кыскартылган, кыскартылма
*лат.* – латинча
*масд.* – масдар, исем фигыль
*мәгъ.* – мәгънәсендә
*мәс.* – мәсәлән
*мзк.* – мөзәккәр
*мнс.* – мөәннәс
*син.* – синоним
*сф.* – сыйфат
*тәм-маган* – фигыльнең тәмамланмаган төр формасы
*төр.* – төрекчә
*төш.* – төшем юнәлеше
*тур.* – турында
*урт.* – уртак грамматик җенес
*фар.* – фарсыча
*фкһ.* – фикъһ сүзе
*хал.* – халык сөйләме сүзе
*чаг.* – чагыштырыгыз
*энд.* – эндәшү формасы

## ГАРӘП ӘЛИФБАСЫ

| Хәрефнең язылышы | Хәрефнең исеме | Хәрефнең язылышы | Хәрефнең исеме |
|---|---|---|---|
| ا (آ) | әлиф | ض | д̣а̄д |
| ب | бə̄ | ط | т̣а̄ |
| ت | тə̄ | ظ | з̣а̄ |
| ث | с̱ə̄ | ع | ‘айн |
| ج | жӣм | غ | г̣айн |
| ح | х̣ə̄ | ف | фə̄ |
| خ | х̱а̄ | ق | қ̣а̄ф |
| د | дə̄л | ك | кə̄ф |
| ذ | з̱ə̄л | ل | лə̄м |
| ر | ра̄ | م | мӣм |
| ز | зə̄ | ن | нӯн |
| س | сӣн | ه (ة) | hə̄ (тə̄) |
| ش | шӣн | و | ва̄у |
| ص | с̣а̄д | ى | йə̄ |